НИГЕЗЛӘМӘ
«Тел, җәмгыять һәм мәгълүмати технологияләр» –
«Язык, общество и информационные технологии»
V Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе

20-21 февраль, 2026 ел
Казан шәһәре

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Тел, җәмгыять һәм мәгълүмати технологияләр» – «Язык, общество и информационные технологии» (алга таба – Конференция) V Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясенең статусын, максатын, бурычларын һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Конференция Татарстан Республикасы Иҗтимагый Палатасы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе ярдәмендә «Белем.ру» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Татнетны үстерү фонды» коммерцияле булмаган оешмасы һәм Казан шәһәренең 16 нчы номерлы татар-инглиз гимназиясе тарафыннан үткәрелә.

1.3. Конференция мәгълүмати һәм цифрлы технологияләр үсеше шартларында шәхес, җәмгыять, мәдәният, тел һәм коммуникация үзенчәлекләрен үстерү мәсьәләләренә багышланган.

## 2. Конференциянең максаты һәм бурычлары

2.1. Конференциянең максаты – мәгълүмати һәм цифрлы технологияләр үсеше шартларында заманча җәмгыять, мәдәният һәм телләр проблемаларын тикшерү, чишелеш юлларын табу.

2.1. Конференциянең бурычлары:

1) җәмгыятьтә телләрнең яшәеше һәм мәгълүмати технологияләрне үстерү өлкәсендә иң актуаль проблемаларны һәм процессларны комплекслы дисциплинаара тикшерү;

2) Интернет челтәрендә тел яшәешенең заманча тикшеренүләренең яңа тенденцияләре, технологияләре һәм үсеш үзенчәлекләре белән бәйле мәсьәләләр буенча фикер алышу;

3) Интернет-киңлеккә күчү шартларында телләрнең үзгәрешен һәм җайлашуын өйрәнүгә һәм иң әһәмиятле юнәлешләргә кагыла торган проблемаларны тикшерү;

4) күпмилләтле Россиянең полимәдәни/полилингваль булуы шартларында Россия граждан тиңдәшлеген формалаштыру һәм җаваплы, продуктив интеллектуаль, оештыру, җитештерү эшчәнлегенә әзер яшьләрне тәрбияләү мәсьәләләре буенча фикер алышу;

5) тәҗрибәне фәнни-методик, инновацион, педагогик һәм иҗтимагый эшчәнлектә гомумиләштерү.

## 3. Конференциядә катнашучылар

3.1. Конференциядә җәмәгать эшлеклеләре, фәнни һәм педагогик хезмәткәрләр, аспирантлар, студентлар, шулай ук муниципаль һәм иҗтимагый оешмаларның кызыксынучы вәкилләре катнаша ала.

## 4. Конференция юнәлешләре

4.1. Конференция программасы юнәлешләре:

1. Цифрлы чорда телләр һәм мәдәниятләр диалогы: Россия халыклары телләрен саклау һәм үстерү өлкәсе буларак киберкиңлек;
2. Локаль телләрне һәм диалектларны саклау, туган якны өйрәнүне һәм туризмны үстерү буенча IT-проектлар: региональ һәм муниципаль практикалар;
3. Мәгълүмати медиакиңлектә массакүләм коммуникация: челтәр басмаларында, блогларда, мессенджерларда һәм социаль челтәрләрдә тел стратегияләре;
4. Цифрлы гуманитар фәннәр һәм тел белән әдәбиятны өйрәнүдә һәм укытуда инновацион технологияләр;
5. Мәгълүмати һәм лингвистик иминлек проблемалары: челтәрдә манипуляцияләргә, фейкларга һәм экстремистик контентка каршы тору;
6. Тел белән бәйле профессияләрнең киләчәге: цифрлы трансформация шартларында лингвист, тәрҗемәче, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе компетенцияләре;
7. Шәхес һәм җәмгыятьнең виртуаль хезмәттәшлегенең психологик һәм этик аспектлары: социализациянең яңа формалары, кибербуллинг һәм этикет;
8. Ясалма интеллект, тел һәм җәмгыять: мәгариф, фән һәм этика өчен заман таләбе (чат-ботлар, нейрочелтәрләр, машина тәрҗемәсе).
9. Мәгълүмати җәмгыятьтә медиамәдәният һәм әдәбият: туган телдә әдәбиятны саклау һәм популярлаштыруның цифрлы стратегияләре.
10. Цифрлы күптөрлелектә бердәмлек: гомуми социомәдәни киңлектә Россия халыклары телләренә һәм мәдәниятләренә ярдәм итү өчен цифрлы чишелешләр.

## 5. Конференция үткәрелү вакыты һәм тәртибе

5.1. Конференция ике этапта үткәрелә:

I этап: 2026 елның 26 гыйнварыннан 10 февраленә кадәр – гаризалар һәм тезислар кабул итү.

II этап: 20-21 февраль – конференция (пленар утырыш һәм секцияләр).

5.2. Конференция үткәрелү датасы һәм урыны:

- 20.02.2026, 10:00 сәг. башлана – пленар утырыш, Татарстан Республикасы Иҗтимагый Палатасы (Казан шәһәре, Батурин урамы, 7А йорт);
- 21.02.2026, 10:00 сәг. башлана – секцияләр эше, Казан шәһәренең 16 нчы номерлы татар-инглиз гимназиясе (Казан шәһәре, Дубравная урамы, 51А йорт).

5.3. Конференциядә катнашу түләүле – 700 сум. Акча күчерү өчен реквизитлар:

Счет получателя:
40702810000000027969
Получатель: Общество с ограниченной ответственностью «Белем.ру»
ИНН получателя: 1661018513
КПП получателя: 165501001
Банк получателя: АКБ «Энергобанк» (АО)
БИК банка получателя: 049205770
Корр. счет банка получателя:
30101810300000000770

Тиз түләү өчен QR-код:

Түләүне тиз башкару өчен сылтама: https://qr.nspk.ru/BS2A004CF7PFICEA8GEOC21PMAPOIF2N?type=01&bank=100000000159&crc=3655

5.4. Конференция программасы оештыру комитеты тарафыннан төзелә һәм пленар утырышны, секцияләр эшен, йомгак ясауны күз алдында тота.

5.5. Конференциядә катнашуга аерым авторларның (физик затларның), эшче төркемнәрнең (2 кешедән артмаган) эшләре рөхсәт ителә.

5.6. Конференциядә катнашу өчен 2026 елның 10 февраленә кадәр, https://forms.yandex.ru/cloud/6969f6a4e010db2450425985 сылтамасы буенча анкетаны тутырырга, тезисны (2 биткә кадәр күләмдә) һәм түләү квитанциясен беркетергә кирәк.

5.7. Конференциядә катнашучының анкетада язылган электрон почта адресына Конференциягә чакыру һәм Конференция программасы җибәрелә.

Юл, яшәү, туклану чыгымнары оешма яисә катнашучы тарафыннан мөстәкыйль башкарыла.

5.8. Билгеләнгән вакыттан соң җибәрелгән, күрсәтелгән кагыйдәләрне үтәмичә тапшырылган материаллар Конференциянең оештыру комитеты тарафыннан кабул ителми.

5.9. Конференциянең эш телләре – рус, татар.

5.10. Материалларның дөреслеге һәм авторлык хокуклары өчен мәкалә авторы җаваплы.

5.11. Конференциягә җибәрелгән мәкаләнең тезис тутыру таләпләре.

Тезис күләме 2 биттән артмаска, Microsoft Word редакторында башкарылырга тиеш: бит китап ориентацияле, А4 форматы, битләр периметры буенча 2 см лы кыр, Times New Roman шрифты, шрифт үлчәме – 14 пт, юллар арасындагы интервал – 1,5; битнең киңлеге буенча тигезләү, абзац чигенеше – 1,25 см («Tab» яисә «Буш ара» клавишаларын кулланмыйча). Битләргә номерлар куелмый.

Тезисның исеме үзәктә, ахырда ноктасыз, баш хәрефләр белән языла. Тезис исеменнән соң үзәктә ярыминтервал аша мәкалә авторы, вазифасы, эш/уку урыны күрсәтелә.

Тезиста сайланган теманың актуальлеге, бурычлар, тикшеренү предметы, эшнең гамәли кыйммәте булырга тиеш. Мәкаләдә кулланыла торган әдәбият чыганакларына Чыганаклар исемлегендә номеры буенча авыш җәяләрдә сылтамалар күрсәтелгән булырга тиеш.

Чыганаклар исемлегендәге әдәбиятны текстта сылтамалар барлыкка килү тәртибендә урнаштыралар һәм ГОСТ нигезендә эшлиләр.

*Мәкаләне язу үрнәге*

TATARICA ОНЛАЙН ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНЕҢ
МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН КОНКУРСЛАР УЗДЫРУ ТӘҖРИБӘСЕ

*Фазлыйәхмәтова Гөлнара Илдар кызы,*
*Татарстан Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе*
*һәм төбәкне өйрәнү институты фәнни хезмәткәре,*
*Казан шәһәре*

Мәкалә тексты...

ЧЫГАНАКЛАР ИСЕМЛЕГЕ:

1. Мәхмүтов Х. Татар халкының афористик иҗаты / Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр / Х.Ш. Мәхмүтов. - Казан: Татар. кит. нәшр., 1995.- 173 б.

2. Фазлиахметова Г.И. Определение портрета пользователя онлайн–энциклопедии Tatarica // История России и Татарстана: Итоги и перспективы энциклопедических исследований: Сборник статей итоговой научной конференции научных сотрудников Института татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ (г. Казань, 27 мая 2021 г.) / Институт татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ. – Казань, 2021. – Вып. 13. – С. 71–79.

3. Tatarica. Татар энциклопедиясе [Электронный ресурс]. – URL: https://tatarica.org/tat (дата обращения: 14.02.2025).

4. …

## 6. Конференциянең оештыру комитеты

6.1. Конференциянең оештыру комитеты түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

- эксперт комиссиясе составы һәм рәисне билгеләү турында карар кабул итү;
- расланган план нигезендә конференция кысаларында мәгълүмати чаралар үткәрү;
- конференция партнерлары белән эшне координацияләү;
- тикшерену эшләрен бәяләү критерийларын раслау;
- конференциядә катнашу өчен җибәрелгән эшләрне кабул итү;
- эшләрне рәсмиләштерүнең әлеге Нигезләмәдә каралган таләпләргә һәм шартларга туры килүен тикшерү, эшләрне плагиатка тикшерү;
- эшләрне теркәү, эксперт комиссиясе эшләрен тапшыру;
- конференция үткәрелгән вакытта эксперт комиссиясе эшен координацияләү;
- конференциядә җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын оештыру.

6.2. Элемтә өчен телефон: +7 960 045-63-53 (шул исәптән: Telegram); e-mail: academy.belem@yandex.ru.

## 7. Конференциянең Экспертлар комиссиясе

7.1. Конференциянең Экспертлар комиссиясе иң яхшы эшләрне сайлап алу һәм бәяләү методикасы һәм бәяләү критерийлары нигезендә җиңүчеләрне билгеләү максатыннан төзелә. Секциянең эше тәмамлангач, комиссия аңа нәтиҗәләр ясый. Конференциядә катнашучыларның эшенә рецензияләр бирелми. Экспертлар комиссиясе составы Конференциянең Оештыру комитеты тарафыннан төзелә һәм раслана.

## 8. Эшләрне бәяләү критерийлары

8.1. Эшләрне бәяләү критерийлары:

1) Актуальлек (0-5 балл);

2) Эшнең яңалыгы, инновациялелек (0-5 балл);
3) Эчтәлек сыйфаты, темага туры килү (0-5 балл);
4) Гамәли өлеш, тикшеренү нәтиҗәләре (0-5 балл);
5) Чыгыш. Тел грамоталылыгы (0-5 балл).

**9. Конференциягә нәтиҗәләр ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү**

9.1. Докладлар секция утырышларында тыңланыла, эксперт комиссиясе тарафыннан бәяләнә. Комиссия конференциянең җиңүчеләрен һәм призерларын билгели.

9.2. Конференциядә җиңүчеләр һәм призерлар дипломнар белән бүләкләнә.

9.3. Конференциядә катнашучыларга сертификат һәм конференция материаллары җыентыгы тапшырыла.

# ОЕШТЫРУ КОМИТЕТЫ СОСТАВЫ

**Оештыру комитеты рәисе:**

Гатауллин Раил Мәүлет улы – «Белем.ру» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры, «Татнетны үстерү фонды» коммерцияле булмаган оешмасының башкаручы директоры

**Оештыру комитеты әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Кадыров Тимур Рәфкать улы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый Палатасы рәисе урынбасары |
| Мөбәракшина Эльмира Рафис кызы | «Татарстан Республикасы цифрлы трансформация үзәге» Дәүләт казна учреждениесенең Мәдәният, мәгариф һәм яшьләр сәясәте өлкәсендә цифрлы трансформация бүлеге башлыгы |
| Халиков Илгиз Илдар улы | Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры |
| Хисмәтова Лилия Котдус кызы | «Мәгариф» журналының баш мөхәррир урынбасары, «Компетенцияләр мәктәбе» автоном коммерцияле булмаган оешмасы директоры |
| Хәлимова Гөлфия Мансур кызы | Казан шәһәре Идел буе районының 16 нчы номерлы татар-инглиз гимназиясе директоры |
| Минубаева Алия Юлай кызы | Казан шәһәре Идел буе районының 16 нчы номерлы татар-инглиз гимназиясе директор урынбасары |
| Шакирова Алсу Рәшит кызы | Казан шәһәре Идел буе районының 16 нчы номерлы татар-инглиз гимназиясе директор урынбасары |